РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Елантовского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Елантау авыл җирлеге
Советы

423597, Нижнекамский район,
с. Елантово, ул. Нагорная, 1г

423597, Түбән Кама районы,
Елантау авылы, Нагорная урамы, 1г

тел. /факс (8555) 33-30-42, электронный адрес: Elant.Nk@tatar.ru, сайт: www. elantovskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

22.07.2021 ел № 04/12-25

Елантау авыл җирлеге Советының «Елантау авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 20 декабрендәге 52-102 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9, 142.3, 142.5 статьялары, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы « Елантау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 31 статьясы нигезендә, Елантау авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Елантау авыл җирлеге Советының «Елантау авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 20 декабрендәге 52-102 номерлы карары белән (алга таба – карар) расланган Елантау авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 Тәртипнең 3 бүлегендәге 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүче булып, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлеге башкарма комитеты тора.».

1.2 Тәртипнең 3 бүлегендәге 6 пункты 6.3 пунктчасының 2 абзацын һәм 4 бүлегендәге 3 пунктын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Елантау авыл җирлеге
башлыгы В.А. Лебедев